# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“25” ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 25ноябрендә «Сез 2021 елда Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- Мәчет бинасыннан алып К. Маркс һәм Ленин урамнары чатына кадәр юлдагы барлыкка килгән чокырларга вак таш җәю, транспорт хезмәтләре өчен түләү;

- Ленин урамыннан зиратка кадәрге арага вак таш җәеп юл салу, машиналар кую өчен мәйданчык урнаштыру, транспорт хезмәтләре өчен түләү;

2. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

- лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу,урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Ленин урамы буенча 28 - нче номерлы йорт янында елга аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлау, материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү;

- Иске хастаханә бинасын сүтү (калдыкларны утильләштерү, транспорт хезмәтләре һәм башкарган хезмәтләр өчен түләү);

- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү.

4. Күңгәр авылында су чыгару башнясын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 191 (бер йөз туксан бер) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 105 (бер йөз биш) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 105 (бер йөз биш) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2021 елда Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- Мәчет бинасыннан алып К. Маркс һәм Ленин урамнары чатына кадәр юлдагы барлыкка килгән чокырларга вак таш җәю, транспорт хезмәтләре өчен түләү;

- Ленин урамыннан зиратка кадәрге арага вак таш җәеп юл салу, машиналар кую өчен мәйданчык урнаштыру, транспорт хезмәтләре өчен түләү;

2. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

- лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу,урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Ленин урамы буенча 28 - нче номерлы йорт янында елга аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлау, материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү;

- Иске хастаханә бинасын сүтү (калдыкларны утильләштерү, транспорт хезмәтләре һәм башкарган хезмәтләр өчен түләү);

- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү.

4. Күңгәр авылында су чыгару башнясын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Салахов И.И.